ГЛАВА
Иж-Бобьинского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Иж-Бубый авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.10.2020 Иж-Бубый авылы № 03

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башлыгы **к а р а р и т т е:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәг 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2020 елның 12 ноябрендә 14 сәг 00 минутка билгеләргә.
3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә:

- 1 этап: 1 нче Колхоз тыкрыгында, 2 нче Колхоз тыкрыгында, Заречная, Колхозная, Лесная, Молодежная, Татарстан, ТР, Трудовая урамнарында яшәүчеләр.
- 2 этап: Ижевск, Магистраль, Яр буе, Яңа урам, Үзәк урамнары.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә житкән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм

балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Иж-Бубый авылының скважиналары өчен тирәнлек насосларына хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау, Иж- Бубый авылының суүткәргеч челтәрләрен карап тоту һәм төзекләндерү;
- Иж-Бубый авылының Татарстан тыкрыгы, Колхоз, Набережная, Заречная урамнары юлларына вак таш сатып алу һәм җәю
- Иж-Бубый авылының урамнарын кардан чистарту
- Иж-Бубый авылында авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кису
- ДТ-75 НМ тракторын ремонтлау һәм карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иж-Бубый ав., Үзәк урамы, 20 нче йорт янында авыл клубы каршындагы мәйданчыкта үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. ВАҺАПОВ